Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXIII-5**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 4 сентябре

ТатарстанРеспубликасы Балык Бистәсе муниципаль районСоветының2017елның 24 июлендәге XX-10 номерлыкарары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципальрайоны муниципаль милкен хосусыйлаштырухакындагы Нигезләмәгәүзгәрешләр кертүтурында

Муниципаль норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга тәңгәлләштерү максатларында,2001 елның 21 декабрендәге “Дәүләти һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 178-ФЗ номерлы Федераль законга, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2018 елның 31 маендагы “Россия Федерациясенең аерым закон актларында “чит ил инвесторы” төшенчәсен аныклау өлешенә үзгәрешләр кертү турында”гы 122-ФЗ номерлы законнарга туры китереп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципальрайоны Уставының 30 маддәсе нигезендә ТатарстанРеспубликасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.ТатарстанРеспубликасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017елның 24 июлендәгеXX-10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципальрайоны муниципальмилкен хосусыйлаштыру турындагы (ТатарстанРеспубликасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017елның 13 декабрендәгеXXIV-3 номерлы карары тарафыннан кертелгән үзгәрешләр белән) Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 1.5. пунктында:

дүртенче абзацтагы “(алга таба – оффшор компанияләр)” сүзләрен төшереп калдырырга, “, һәм ачуны һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә үзләренең файда алучылары, бенефициар биләүчеләре һәм тикшерүче затлары турында мәгълүмат бирүне гамәлгә ашырмаучылар” сүзләре белән тулыландырырга;

бишенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“”контроль ясаучы зат” төшенчәсе 2008 елның 29 апрелендәге “Ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен стратегик әһәмияткә ия булган хуҗалык җәмгыятьләренә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында”гы 57-ФЗ номерлы Федераль законның 5 маддәсендәге кебек үк мәгънәдә

кулланыла”. “Файда алучы” һәм “бенефициар биләүче” төшенчәләре 2001 елның 7 августындагы “Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (юуга) һәм террорчылыкны финанслауга каршы тору турында”гы 115-ФЗ номерлы Федераль законның 3 маддәсендә күрсәтелгән мәгънәдә кулланыла.”.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы<br>Балык Бистәсе муниципаль<br>район Советы рәисе<br>урынбасары И.Г.Ибраһимов